ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.12.2021 с. Шеланга 13

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Кызыл Байрак авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә ,

Карар бирәм:

1. 2021 елның 21 декабренә Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Кызыл Байрак авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Кызыл Байрак бистәсендәге зиратны төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Кызыл Байрак авылы, Үзәк урамы, 12 нче йорт адресы буенча 11.00 сәгатьтә Кызыл Байрак авыл клубында үткәрергә.

4.Гражданнар җыенын Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров